КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 март г.Казань № 325

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затларны социаль адаптацияләү чаралары турында» 2006 ел, 9 октябрь, 510 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затларны социаль адаптацияләү чаралары турында» 2006 ел, 9 октябрь, 510 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 13 июль, 294 нче; 2012 ел,15 май, 372 нче; 2017 ел, 28 август, 605 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләренә мөрәҗәгать иткән билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар белән эшләгәндә ведомствоара хезмәттәшлек тәртибенең 2 пунктында «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләренә мөрәҗәгать иткән билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затларга ярдәм күрсәтү тәртибендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләренә (алга таба – Үзәкләр) мөрәҗәгать иткән билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затларга ярдәм күрсәтү тәртибе Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы ведомстволары һәм учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.»;

2 пунктның бишенче абзацында «граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы» сүзләрен «Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы» сүзләрен «Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча шәһәрдәге (районндагы) идарәсе (бүлеге)» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин